**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**АЛАБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422373 с. Алабердино, ул. Ленина, 71

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЛАБИРДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422373 Алабирде авылы, Ленин урамы, 71

тел. (84373) 5-80-37, факс 5-80-37, e-mail:Alab.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606557213, ИНН/КПП 1638002272/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**06 .12. 2022** **№ 16-1**

**2023 елга 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Алабирде авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1 нче маддә

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджетының фаразлана торган гомуми керем күләме 1652,93 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең бюджет чыгымнарының гомуми күләме 1652,93 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең бюджет дефициты 0,00 мең сум.

2. 2024 елга һәм 2025 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2024 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджетының фаразлана торган гомуми керем күләме 1678,08 мең сум һәм 2025 елга 1725,65 мең сум күләмендә;

2) 2024 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1678,08 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-38,60 мең сум һәм 2025 елга 1725,65 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-79,40 мең сум;

3) 2024 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең бюджет дефициты 0,00 мең сум һәм 2025 елга 0,00 мең сум күләмендә.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2 нче маддә

1. 2024 елның 1 гыйнварына Алабирде авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген расларга

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Алабирде авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Россия Федерациясе валютасында нульле әһәмияткә ия.

2. 2025 елның 1 гыйнварына Алабирде авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген расларга

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге Россия Федерациясе валютасында.

3. 2026 елның 1 гыйнварына Алабирде авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген расларга

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Алабирде авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиге

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Россия Федерациясе валютасында нульле әһәмияткә ия.

3 нче маддә

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджетында әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына фаразланган керем күләмнәрен исәпкә алырга.

4 нче маддә

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет чыгымнарын классификацияләү чыгымнары төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга

2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2023 елга 0,00 мең сум, 2024 елга 0,00 мең сум һәм 2025 елга 0,00 мең сум күләмендә расларга.

5 нче маддә

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә), шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

6 нче маддә

Тышкы муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлешендә төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Тәтеш муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

2023 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2024 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2025 елга 1,00 мең сум күләмендә.

7 нче маддә

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге

бюджетында Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан алучыларны исәпкә алырга

1) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:

2023 елга - 1080,60 мең сум күләмендә;

2024 елга - 1088,70 мең сум күләмендә;

2025 елга - 1126,30 мең сум.

2) территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр:

2023 елга-126,43 мең сум күләмендә;

2024 елга-132,38 мең сум күләмендә;

2025 елга - 137,25 мең сум.

8 нче маддә

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2023 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

9 нчы маддә

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде авыл җирлеге бюджеты үтәлеше буенча аерым функцияләр башкара.

10 нчы маддә

Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 нче маддә

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Җитәкче урынбасары** **Т.Г. Фәтхуллин**